**ТАТАРСТАН Республикасы**
**Аксубаймуниципальрайоны**
**муниципальберемлеге**
**Емелькиноавылы**

**Республика ТАТАРСТАН**
**Аксубаевский**
**муниципальный район**
**муниципальное образование**
**село Емелькино**

## СоветЕмелькинского сельского поселения

423056, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, село Емелькино, ул. Центральная д.16
Тел.(8-84344-4-76-22) ОГРН 1021605364980, ОКПО 94318599,ИНН/КПП 1603000796/160301001

**КАРАР**

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге составына керүче Сосновка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

14 декабрь 2023 ел № 9

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы» Емелькино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уставы 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Советының 05.11.2019 № 100 «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карары белән, 2023 елның 15 декабрендә түбәндәге сораулар буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:
:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегенең Сосновка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 10.11.2023 елгы гражданнар җыенының карарын гамәлдән чыгарырга

2. 2024 елда Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегенең Сосновка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, (I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, хәрби хезмәткә чакырылган, өлешчә мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары, контракт буенча хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш), 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1.Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны кышкы тоту, килешү буенча эш өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

2.Күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру;

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне кисү - ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, трактор һәм аларга комплектлаучы җиһазлар сатып алу)

- Урамнарны яктырту җайланмасы (торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен килешү буенча товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;)

РИЗА» «КАРШЫ». «ТЫЕЛДЫМ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 68 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 38 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән::
- "риза"позициясе өчен 38 граждан тавыш бирде;
- "каршы"позиция өчен 0 граждан тавыш бирде.
-"тыелдым » позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде

Югарыда әйтелгәннәр нигезендә, гражданнар җыены КАРАРы:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегенең Сосновка авылындагы гражданнар җыены узган дип , гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылсын.

2.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегенең Сосновка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 10.11.2023 елгы гражданнар җыенының карарын гамәлдән чыгарырга

3. Мәсьәлә буенча карарны КАБУЛ дип тану: Сез 2024 елда Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегенең Сосновка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, (I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, хәрби хезмәткә чакырылган, өлешчә мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары, контракт буенча хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш), 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1.Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны кышкы тоту, килешү буенча эш өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

2.Күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру;
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне кисү - ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, трактор һәм аларга комплектлаучы җиһазлар сатып алу)
- Урамнарны яктырту җайланмасы (торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен килешү буенча товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;)

3. Әлеге карарны Емелькино авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://aksubaevo.tatar.ru, һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
ТР Аксубай муниципаль районы
Емелькино авыл җирлеге башлыгы: Н.И.Михайлова